**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя
Каменка, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә
авылы, 423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 19 22 март 2021 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 октябрендәге123 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Чирмешән муниципаль районының «Югары Кәминкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2019 елның 1 октябрендәге 123 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1) 1.7 пунктта өченче, дүртенче, бишенче абзацларны төшереп калдырырга;

2) 2.10 пунктта «Гражданнар җыены турындагы нигезләмә нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 3.7 пунктта «(вариант буларак: форма Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 3.13 пунктында «(вариант буларак: форма Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән билгеләнә)» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (PRAVOTATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **М.Н.Мингазов**